| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>СОВЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» декабрь 2024г. г. Альметьевск №334

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 242 номерлы «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 21 сентябрендәге 820 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 242 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 30 октябрендәге 9 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 137 номерлы, 2022 елның 5 октябрендәге 167 номерлы, 2022 елның 31 октябрендәге 172 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 187 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 297 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| «Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад күләмнәре, сум |
|---|---|
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 19 027 |

| | |
|---|---|
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 18 467 |
| Бүлек башлыгы | 17 768 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 16 928 |
| Баш белгеч | 16 089 |
| Әйдәп баручы белгеч | 15 250 |
| I категорияле белгеч | 14 270 |
| II категорияле белгеч | 14 130 |
| Белгеч | 13 990» |

1.2. карарага 2 нче кушымта таблицасында «13 323» санын «13 990» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү җирле бюджет акчалары исәбеннән башкарыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»на (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнвареннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Туманова Г.П.).

Муниципаль район
Башлыгы урынбасары А.А. Зимин

СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА